КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 август

г.Казань

№ 661

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирә торган белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын бүлүгә конкурс үткәрү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирүче белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнар кабул итүнең контрольдә тотыла торган саннарын бүлүгә конкурс үткәрү комиссиясе турында» 2015 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 10 апрель, 235 нче; 2016 ел, 13 май, 302 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 972 нче; 2017 ел, 4 октябрь, 757 нче; 2018 ел, 9 апрель, 217 нче; 2019 ел, 6 сентябрь, 788 нче; 2020 ел, 17 сентябрь, 842 нче; 2021 ел, 20 август, 752 нче; 2022 ел, 13 август, 812 нче; 2023 ел, 1 август, 926 нчы

карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирүче белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнар кабул итүнең контрольдә тотыла торган саннарын бүлүгә конкурс үткәрү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан Ю.Р.Миңнуллинны, Р.И.Һидиятуллинны чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Габдрахманов Булат Фәнил улын | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасарын |
| Сираҗиев Сәрия Салих кызын | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасарын; |

Родион Михайлович Карповның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин